**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 23 » 08 2018 ел № 183

Азнакай муниципаль районы территориясендә җирләү
эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган оешманы
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварендагы 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә карар бирәм:

1. «Азнакай шәһәрен төзекләндерү һәм яшелләндерүнең күптармаклы җитештерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесен Азнакай муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча билгеләргә.

2.«Азнакай шәһәрен төзекләндерү һәм яшелләндерүнең күптармаклы җитештерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба - предприятие) директорына:

2.1. Предприятие Уставына 2018 елның 15 сентябренә кадәр үзгәрешләр кертергә;

2.2. Эшләргә:

- түләүсез һәм түләүле нигездә күмү хезмәтләрен башкару бәяләренең прейскурантын;

- Азнакай муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган оешма эшчәнлеге тәртибе турында нигезләмәне.

3.Әлеге карарны «веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы: http//pravo. tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга веб-адрес: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов